Чыганак: Сагына Киме, сагына бөтен илем сөекле улын – халык җырчысын : татар теле һ. әдәбияты укытучылары, студентлар өчен метод. кулланма / төз. : З. Н. Җиһаншина ; ф. мөх-ре: Р. Р. Харрасова. – Казан : ГБУ «Республиканский центр мониторинга качества образования», 2013. – 148 б.

# ТУГАН ЯКТАҺӘР ТАЛ ҖЫРЛЫЙ

## (Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә)

*Г.Н. Шәяхмәтова,*
*Яр Чаллы шәһәре, 51 нче мәктәп*

**Максат**: укучыларны С. Хәкимнең иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; туган якка мәхәббәт, башка халыкларны ихтирам итү хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** С. Хәким портреты, китаплары күргәзмәсе, компьютерда презентация.

*1 алып баручы.* Игътибар! Тыңлагыз! Узган гасырдан тарих аваз сала.

*2 алып баручы.* 100 ел элек 4 нче декабрьдә Әтнә районы Күлле-Киме авылында шагыйрь дөньяга килә.

*1 алып баручы.* Шагыйрьнең дә нинди әле! Халык шагыйре! Ул Россиянең Максим Горький, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге бүләкләренә лаек булды, 1986 нчы елда аңа «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

*2 алып баручы.* Бүгенге бәйрәм кичәсен Сибгат Хәкимгә багышлыйбыз.



*1 алып баручы.*

Ходай аның шигъри талантына
Өстәп биргән бөек сабырлыкны:
Йомшак кына елмаюы белән
Җиңеп барган күпме авырлыкны...
Уйчан гына балкып йөрсә дә шул,
Көчле рухлы булган Сибгат ага!
Әле дә булса «Җылы сүзе» белән
Шигърияткә безнең учак яга.
Сүз ишетелә сүзләр арасыннан:
«Хәким кебек яшәп карасыннар!..»
Җанга каткан бозлар эреп агар
Җылы сүзе, җылы карашыннан.
(«Йомшак кына елмаюы белән». Лена Шагыйрьҗан)

*2 алып баручы.* С. Хәким мәктәп елларында ук шигырьләр яза башлый, әдәбиятка тартыла. Туган як шагыйрьне нечкә күңелле, игелекле, халыкның гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карауЧы итеп үстерә. Халык моңнары шагыйрь күңеленә мәңгелеккә кереп кала: «Ә халыкның үз җырлары! Аның характерына хас ниндидер уйчан, тыйнак моң. Әйтерсең лә алар халыкның үз язмышыннан саркылып чыкканнар. Йөрәгеңә бер кердеме, тиз генә китмәс, иң түренә, эчкәрегә үк кереп утырыр да мәңгегә калыр...»

*1 алып баручы.* 1930 нчы елда С. Хәким Казанга килә, Татар рабфагына укырга керә, соңыннан педагогия институтына күчә. Казан дәүләт педагогия институтында укыган елларда актив иҗат итә башлый. 1938 нче елны «Беренче җырлар» дип исемләнгән беренче җыентыгы дөнья күрә. Бер-бер артлы «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы» исемле җыентыкларын чыгара.

1 нче укучы «Яратам мин» шигырен сөйли.

2 нче укучы «Юл буенда үскән топольләрнен» шигырен сөйли.

*2 алып баручы.* С. Хәкимгә Туган илне фашист илбасарларыннан азат итәргә туры килә. Ул 1941 нче елның июнь аенда армиягә алына. 1946 нчы елның апреленә кадәр хәрби хезмәттә була. Сугышта ул – рота командиры, артиллерист. Курск дугасындагы атаклы сугыш дәһшәтен исән-имин кичеп, утлы юллар аша үтеп туган якка кайтып егылган, туган туфрактан көч алып, әдәбиятның алгы сызыгына баскан. Шагыйрь үзе фронтта вакытта аның «Юксыну» шигыре халык арасында җыр булып тарала.

«Юксыну» җыры башкарыла. (С. Хәким сүзләре, Шакир Мәҗитов көе)

*1 алып баручы.* С. Хәким иҗаты – киң колачлы, бай иҗат. Заман белән тыгыз бәйләнештә торган шагыйрь буларак, ул тормыш күтәргән мәсьәләләргә җавап эзли, аларга укучыларның игътибарларын юнәлтә. Аның иҗаты тормышчанлык белән тирән сугарылган. Ул үзе күргәнне, белгәнне генә үзенең йөрәге аша үткәреп кичергәнне генә язарга ярата.

*2 алып баручы.* С. Хәкимнең бөтен батырлыгы – җаны, акылы, күз карашлары, сөйләшүләре, атлап йөрүләре, елмаюы – туган җиренә, басуларына, юл-сукмакларына, тауларына, урманнарына, чишмәләренә, шул җирдә яшәгән кешеләр күңеленә килеп кушылып, бербөтенгә әйләнә. Туган як темасы шагыйрьнең бөтен иҗатын иңләп үтә.

*1 алып баручы.* Туган як – мәңгелек моңым,
Һәрнәрсәгә гади, садә.
Күземне тутырып карыйм,
Җирдәге һәрнәрсәгә.

*2 алып баручы.* Бөтенләем белән җирнеке мин,
Минем барлык нәсел-нәсәбем –
Игенчеләр.Җирдән төртеп чыга
Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем.

3 нче укучы «Туган җир» шигырен сөйли.

4 нче укучы «Туган як» шигырен сөйли.



5 нче укучы «Таң атканда» шигырен сөйли.

«Бер тауда ун чишмә» җыры башкарыла. ( С. Хәким сүзләре, Әгъзам Фәттах көе)

*1 алып баручы.* Әдип иҗатының күп өлеше авыл тормышы, аның хезмәт сөюче кешеләре, Күлле Киме белән бәйле була. Ул туган ягы белән бәйләнешне өзми, һәр елны туган төбәгенә кайтып, кешеләре белән аралаша, иҗат итә.

*2 алып баручы.* Авыруыма врач кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын:
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.
Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

*1 алып баручы.* Туган җир матурлыгын сурәтләп язган әсәрләре шигъриятнең иң югары ноктасын билгеләп кенә калмыйча, татар поэзиясенең уңышлы әсәрләре арасында урын алдылар.

*2 алып баручы.* Шагыйрьнең шигырьләре көйгә салынып, халкыбызның рухи чишмәсенә әверелделәр. Шигырьләрендәге лиризм, гармония, аһәң үзеннән-үзе җыр, көй сорый.

*1 алып баручы.* Туган якта һәр тал җырлый,
Үз-үзенә, тын гына.
Җырлый таллар, җитә эңгер,
Тынмый алар төн була.
Туган якта һәр тал җырлый,
Җырлый таллар төн ката.
Җырлый таллар, җитә иртә,
Тынмый алар, таң ата.

6 нчы укучы «Башка берни дә кирәкми» шигырен сөйли.

7 нче укучы «Әй, язмыш, язмыш» шигырен сөйли.

8 нче укучы «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигырен сөйли.

«Фазыл чишмәсе» җыры башкарыла. ( С. Хәким сүзләре, татар халык көе)

*2 алып баручы.* С. Хәкимнең туган ягы турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйлана. Чөнки туган як белән бәйле тойгы һәркемнең күңеленә газиз, җирсү дигән тетрәндергеч хисне үз гомерендә бер тапкыр гына булса да кичерми калган кешене табуы кыен. Туган як кеше өчен кадерле, изге булырга тиеш. Тормыштагы авыр мизгелләрендә кешеләр туган нигезләренә тартылалар. Безнең туган ягыбыз – Яр Чаллы шәһәре. Шагыйрь безнең данлы калабызга да багышлап шигырьләр иҗат иткән.

*1 алып баручы.* Бар нигезләр бергә буталганда,
Күкрәгемне кайнар ут алганда,
Күргәннәрне теркәп кәгазьгә,
Мин дә йөрдем, йөрдем КаМазда.
Кама бөек һәм тарихы бөек,
Бөтенесен бер танылйсы килеп,
Торам ярда.Чаллы яланнары...
Ишетелми чалгы янаулары.

9 нчы укучы «Яңа шәһәрдә яшь юкә» шигырен сөйли.

10 нчы укучы «Чорлар – баскыч, КаМаз – масштаб» шигырен сөйли.

11 нче укучы «Үз ягы үзенең йөзендә» шигырен сөйли.

*2 алып баручы.* Яз көне шәһәребезнең иң матур урамы – Тынычлык урамы. Ике юл уртасында алмагачлар шау чәчәктә. Аларга сокланмаган юлчы юктыр. С. Хәким «КаМАЗ алмагачлары» дигән шигырен аларга багышлагандыр.

12 нче укучы «КаМАЗ алмагачлары» шигырен сөйли.

«Сусау» җыры башкарыла. (С. Хәким сүзләре, Сара Садыйкова көе)

*1 алып баручы.* Шагыйрь иҗатында аеруча калку чагылган тагын бер тема – халыклар дуслыгы темасы. Балачагы, яшьлеге мари авыллары тирәсендә үткәнгә, әдип татар һәм



мари халыкларының үзара дуслыгына, хезмәттәшлегенә дан җырлый. Әсәрләрендә ике халыкның бер-берсенә ихтирамы, дуслык хисләре ачык чагыла.

13 нче укучы «Мари кызы Улина» шигырен сөйли.

14 нче укучы «Тарлюк» шигырен сөйли.

15 нче укучы «Кадерле почмак» шигыреннән өзек сөйли.

...Ягымны мин татар, мари катыш
Базарлары белән яраттым.
Базарлары...миңа нәрсә калган
Кысылы-кысыла кереп тормышка?
Әгәр мари төяп килгән утынын
Танышына шунда бурычка
Биреп торса, ничек куандым мин.
Буялсыннар дегет, күмергә.
Күңелем минем шул кешеләрне ич
Зарыга иде кабат күрергә.
Казылмалы юллар, комлы юллар
Таласа да йөрәк шатлыгын,
Шул кешеләр мари урманының
Алып килә монда сафлыгын.
Алып килә иске моңнарын да.
Шуңа гына инде үкенәм:
Сүзләренә күпме колак салдым,
Узмаганмын «кинде үке»дән.
Күпсенмәдем мари басуына
Безнең өстән киткән яңгырны;
Күпер калды...Бер салават күпере
Тоташтырды ике ягымны...

*2 алып баручы.* Шагыйрь күңеле халыклар дуслыгы дигән бөек хисне дими тоеп яши. С. Хәким поэзиясендәге интернационализм һәр әсәренең тукымасына сеңгән. Халыклар дуслыгы Бөек Ватан сугышында да сыналды. Шагыйрьнен дала җыры поэмасында да чагылыш таба.

1 алып баручы. С. Хәким поэзиясе рус әдәбиятына, рус халкына, рус культурасына тирән ихтирам хисе белән сугарылган. Шагыйрь А.С. Пушкин алдында баш ия.

Шагыйрь белән халык йөрәген мин
Охшатамын ике чакмага:
Очрашсалар бергә – очкын оча,
Җырга күчә, илдә саклана.

16 нчы укучы «Пушкин бар» шигырен сөйли.

*2 алып баручы.* С. Хәким шигъри осталыгы иң югары ноктасына җиткән шагыйрьләрдән иде. Шигырьләрнең ритми төзелеше һәм рифмаларының оригинальлеге җәһәтеннән дә, темаларның яктыртылышы, лирик моңның куәте белән дә үзенә тиңнәрне белмәде. Аның иҗаты – халык күңелендә җуелмас урын алган бетмәс, корымас шигърият чишмәсе.

Ялгышмый халык, белә ул –
Күпме еллар үтмәсен.
Адашмый эзләп килә ул
Ихлас җырлар чишмәсен –
Саф шигърият чишмәсен,
Безнең Сибгат чишмәсен!

17 нче укучы.

Яланнарда йөри шагыйрь...
Ул тын гына моңлана.
Әллә шагыйрь, әллә кошлар
Бер-берсеннән моң ала?!
Күпме моң туа җанында
Ә күпмесе – бөредә.
Сибгат Хәким моңы белән
Сайрый кошлар биредә.
Тын гына җырлый үзе дә,
Тын моңы- күптән таныш.
Ул – тамак төбеннән түгел,
Җаныннан чыккан тавыш.



Шагыйрьне бу яланнарга
Туачак МОҢ, Көй дәшә.
Гөлләргә шигырь укый ул,
Урман белән сөйләшә.
Агачларга, үләннәргә
Кагыла ул сак кына.
Ул бит шагыйрь генә түгел –
Тылсымчы да чак кына.
Яланнарда йөри шагыйрь...
Юкка гына йөрмидер:
Җанында Гамь, Моң,
Җыр, Шигырь
Берөзлексез дөрлидер.
Ни булмас шагыйрь җанында –
Үзе белә ул ансын.
Яланнарда йөри шагыйрь...
Бүлдермәгез – уйлансын!
Бүлдермәгез – моңлансын!

(«Яланнарда йөри шагыйрь» Р. Миңнуллин)

## СИБГАТ ХӘКИМ ПОЭЗИЯСЕНДӘ ТУГАН ЯК ТЕМАСЫ

***Н. Михайлова,***
*МБГБУ «Тау Иле урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе:* ***Д.С. Шакирова***

### Кереш

«Сибгат Хәким поэзиясендә туган як темасы» дип исемләнгән фәнни-эзләнү эшенең чыганагы – С. Хәкимнең танылган лирик шагыйрь булуында.